**Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Югары Чыршылы авыл җирлеге составына керүче Усай торак пунктында гражданнар җыены карары**

№ 1

13 ноябрь 2020 ел

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Югары Чыршылы авыл җирлеге составына керүче Усай торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2020 елның 13 ноябрендә уздырылган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән беркетмә төзелде: «2021 елда һәр балигъ булган гражданнан 300 сум күләмендә үзара салым кертүгә килешәсезме?", Сарман муниципаль районы Югары Чыршылы авыл җирлеге территориясендә теркәлгән ,1 Төркем инвалидларыннан, вакытлы хәрби хезмәт үтүче гражданнардан, көндезге уку йортлары студентларыннан тыш, һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү дә керә:

-Усай т. п. Азин ур., Совет ур., авыл эчендәге юлларны ремонтлау (вак таш, асфальт түшәү);

-махсуслаштырылган техника - МТЗ-82.1 тракторына хезмәт күрсәтү (ягулык-майлау материаллары сатып алу);

-артезиан скважиналары территориясен төзекләндерү (төзелеш материаллары, буяулар сатып алу; Усай т. п. коймалар, буяу эшләре өчен түләү);

«ЭЙЕ ЮК»

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 60 кеше, халык җыенында катнашучылар саны 32 кеше кертелгән.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

"Әйе» позициясе өчен халык җыенында катнашучы 32 кеше тавыш бирде;

«юк» позициясе өчен җыенда катнашучы 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Югары Чыршылы авыл җирлегенең Усай авылында халык җыены булып узды, халык җыены нәтиҗәләре - чын мәгънәсендә.

2. "Югары Чыршылы авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган, 1 Төркем инвалидларыннан, вакытлы хәрби хезмәт үтүче гражданнардан, көндезге уку йортлары студентларыннан тыш, 2021 елда 300сум күләмендә үзара салым акчаларын кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне үтәүгә җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерүгә җибәрүгә килешәсезме?:

-Усай т. п. Азин ур., Совет ур., авыл эчендәге юлларны ремонтлау (вак таш, асфальт түшәү);

-махсуслаштырылган техника - МТЗ-82.1 тракторына хезмәт күрсәтү (ягулык-майлау материаллары сатып алу);

-артезиан скважиналары территориясен төзекләндерү (төзелеш материаллары, буяулар сатып алу; Усай т. п. коймалар, буяу эшләре өчен түләү);

3. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен Югары Чыршылы авыл җирлеге Советының мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән,Татарстан Республикасы хокукый мәгълумат рэсми порталында http: //pravo.tatarstan.ru., Сарман муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында http: //sarman.tatarstan.ru. кабул ителгэннэн соң җиде көн эчендә игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Югары Чыршылы авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче
Сарман муниципаль районы
Югары Чыршылы авыл җирлеге башлыгы И.Н.Камалетдинов